ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.09.2021 г.Лениногорск № 94

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2016 елның 28 мартындагы «Лениногорск муниципаль районы территориясендә даими пассажирлар йөртүне оештыру турында» 40 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 11 апрелендәге 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2016 елның 28 мартындагы «Лениногорск муниципаль районы территориясендә даими пассажирлар йөртүне оештыру турында» 40 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль

районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3.4 пунктта «даими рәвештә пассажирлар ташу» сүзләреннән соң «(шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны турында белешмәләрдән тыш)» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны рәсми публикатор «Лениногорские вести» газетасында һәм Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Р.Г. Хөсәенов

Л.М. Галимова
5-44-72